Безнең МИРАС
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
04
апрель 2020
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР • КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР • ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР



## «Сез бетәчәк түгел!»

26 нчы бит

## Каһарман Гали маҗаралары

64 нче бит

Безнең мирас №4 апрель 2020

# Гөләйза

*Фәүзия Бәйрәмованың «Гөләйза» әсәре архив документларына нигезләнеп язылган. Романда вакыйга 1827-1868 елларда Чистай ягы – Кыр Шонталасы, Чирүле Шонтала, Актау авылларында бара.*




Казан яулап алынганнан соң өч гасыр вакыт узган. Шуңа карамастан, татар халкын чукындыру сәясәте һаман дәвам итә. Горур татар халкын һаман тез чүктерә алмыйлар. Гөләйзаның әби-бабасын, көчләп чукындырылгач та үз диннәрен тоткан өчен, кара мунчага бикләп, тончыктырып үтерәләр. Татар халкы, төрле газаплар күреп тә – балаларының язмышы кыл өстендә булганда да, мөселманлыктан, иманнарыннан ваз кичмәгән. Хатыннарны, ирләреннән аерып, урыска кияүгә бирәләр, балаларын аерып алып чукындыралар һәм урыс гаиләсенә тәрбиягә бирәләр. Кеше чыдамаслык шартларда да татар динен, иманын, милләтен саклап калган. Алар бары Аллаһ алдында гына тезләнгәннәр. Иман, дин хакына татарлар бөтен авырлыкларга да түзәләр.

Гөләйза чиркәү кенәгәсенә «керәшен» дип язылган, үзе мөселман динен тота, шуның өчен берничә ел буе суд юлында йөри. Судта аңа Пелагея дип эндәшкәнгә ул, кулына күкрәгенә яшереп алып кергән Коръән тотып: «Минем исемем Гөләйза!» – дип кабатлый, бу аның – йөрәк түреннән чыккан протесты. Канаты каерылган кош кебек булса да, Гөләйза, ана арысландай, балаларын яклый. Кечкенә генә татар хатыны да динен, иманын яклагач, ничек инде ул халык җиңелсен! Хәтта дошманнары да татарларга соклана. Тикшерергә килгән алман Мейснер: «Үз абруен белеп, диненә тугрылыкта, үлгәнче аны бирмәячәге ачык. Динен түгел, башындагы түбәтәен дә бирми татар. Ни әйтсәң дә, Чыңгыз хан нәселе шул, борынгы Биләр-Болгарның дәвамчысы», – дип, куркып, сокланып карый. Урыс побы динен алыштырганнарга: «Сез, үз динегезне сатып, безнең дингә сыенган», – дип, аларга җирәнеп карый, чөнки сатлыкларны бер халык та якламый.

Гөләйза – батыр татар хатыны, дошманнарын җиңеп, мәңгелек дөньяга мөселман килеш күчә. Дисбе дә, буыннан-буынга тапшырылып, әсәрнең буеннан-буена дингә тугрылык символы булып бара.

Гөләйзаның әтисе Ишмөхәммәт Уразмәтов бик көчле, акыллы кеше. Ул милләте, гаиләсе өстенә төшкән авырлыкларны күтәрә. Татар байлары, морзалары, кулларыннан килгәнчә, аларга ярдәм итеп торалар. «Татарны, үзеннән кала, беркем дә якламаячак», – ди Гомәр әзи. Ишмөхәммәт: «Ассагыз да, киссәгез дә, хәтта яткырып суйсагыз да, яңадан урыс диненә кайтмаячакбыз», – ди судта сорау алганда.

«Милләтебез алга таба исән калырмы, динен, телен, үзен саклап кала алырмы – һәрберебездән тора». Гөләйзаның әтисе Ишмөхәммәт авызыннан чыккан бу сүзләр бүген дә актуаль. ИншәАллаһ, динебез сакланып калды, телебез генә куркыныч астында. Әсәрдәге Биләр побы дәвамчылары бүген дә исән, тик эш ысуллары гына икенче. Милләттәшләребез тарафыннан ничә гасыр буе күп корбаннар биреп сакланып килгән телебезгә һаман да һөҗүм дәвам итә. Без, бүгенге татарлар, гасырлар дәвамында ничә буын саклап калган телебездән үз ирегебез белән ваз кичәбезмени?!Безнең барыбыз өчен дә изге бит ул туган тел – татар теле. Телне, гореф-гадәтләрне авыл саклап кала диләр иде. Инде авыллар да бетү алдында. Чит тел безгә газиз туган телебез була алмый бит. Телебезне бергәләп саклыйк, сатлык җаннар булмыйк!

***Сиринә Галиева,***
*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре* ■